# Тәрбия сәгате

# Ребус

к=р ,,, 1,4,5ш=т ,,



Аа



50

Мәр

хә

мәт

ле

# «Мәрхәмәт елмаюдан башлана»



Уяндыңмы, елмай!
Көнне башла шулай,
Елмай үз-үзеңә,
Әйтәсе сүзеңә.
Таралыр бар кайгың,
Тыныч калыр җаның,
Күтәр күңелеңне
Бу бәхет түгелме?



# Нәрсә соң ул **мәрхәмәтлелек**?

**Мәрхәмәтлелек** – ул барлык яхшы эшләр, елмаюлы караш, кемгә дә булса булышу, ярдәм итү, хөрмәт һәм ихтирам.



# Ә начарлык нәрсә ул?

**Кешеләргә, хайваннарга, кошларга, табигатькә карата начар мөгамәлә.**



“**Яхшылык күрәсең килсә, яхшылык ит**” диелә татар халык мәкалендә. Ә сез бу мәкальне ничек аңлыйсыз?

**Җавап:**

- **Кешеләргә эшләгән яхшылык сиңа яхшылык булып кайта.**
- **Ә ачулы, тар күңелле булу, башкаларның уңышыннан көнләшү бик начар гадәт. Шуңа күрә шәфкатьле, ярдәмчел булырга, бер-береңә матур, ягымлы сүзләр әйтеп, күңелләрне күтәрергә омтылырга кирәк.**

- Яхшылык итсәң яшер, яхшылык күрсәң, белдер.

# Мәкальләр

| | |
|---|---|
| Мәрхәмәтле сүз, | ә аның игелекле эшләре бизи. |
| Кешене кием түгел, | песи өчен дә әһәмиятле. |
| Көмеш белән мактанма, | шул бәхетле булыр. |
| Кем игелек эшли, | анда дөреслек тә аз. |
| Кемдә игелек юк, | игелек белән мактан. |
| Матурлыкны эзләмә- | игелек эзлә. |

# Яхшылык ит

Әйе, яхшылыкны кеше алдында мактану өчен эшләмиләр. Татар халкында яхшылык ит тә, диңгезгә ташла, балык белер, балык белмәсә халык белер" – дигән әйтем бар. Сез дә бу теләкләрне исегездә калдырыгыз, һәр көнне игелекле гамәлләр кылырга, изге эшләр башкарырга, кешеләргә миһербанлы, шәфкатьле булырга тырышыгыз.

***Бәхетле бала.***

Бәхетле шул баладыр,
кайсы дәресенә күңел бирсә,
Мөгаллимне олуг күрсә,
белергә кушканын белсә,
Сабакка калмаса соңга,
борылмый барса уң-сулга,
Уенга салмаса ихлас—
менә бәхете аның шунда.
*Кешеләргә итеп шәфкать,*
*үзеннән зурга юл бирсә,*
*Бәхетсезләрне кимсетми,*
*егылганнарга кул бирсә.*
*(Г. Тукай)*

# Һәр көн игелек кыл!







# Мәрхәмәтле бул!







***Һич яхшылык эшли алмасаң  син***
***Кешеләргә бик-бик теләп тә, -***
***Яхшы теләк телә,***
***Ул да кайчак***
***Зур көч өстәп куя йөрәккә.***